ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАРЕЧЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗАРЕЧНЫЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | Заречный поселогы | КАРАР

10 декабрь 2019 ел | № 37

2020 елга мәҗбүри яки төзәтү эшләре төрләрен һәм мәҗбүри яисә төзәтү эшләре рәвешендә административ җәза бирелә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында

«Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри эш төрләрен һәм оешмалар исемлеген билгеләү турында» 16.11.2012 ел, ПР-43-6 номерлы Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы Президиумының карарын үтәү йөзеннән (Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексына 2012 елның 8 июнендә кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә), мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләнгән затларны төзәтү, аларда нормаларга, җәмгыять кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалы хезмәткә ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру максатларында), административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 32.13 статьясы нигезендә һәм законлы көченә кергән суд карары буенча административ җәза үтәү рәвешендәге мәҗбүри эшләрнең мәҗбүри хезмәт булып саналуын исәпкә алып, Заречный авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елга Заречный авыл җирлеге территориясе чикләрендә мәҗбүри яки төзәтү эшләре башкару өчен хөкем ителүчеләр тарафыннан мәҗбүри яки төзәтү эшләре төрләрен, җинаятьләрне үтәтү инспекциясе белән килештереп, билгеләргә: территорияләрне чистарту, яшелләндерү, җир эшләре, юл буйларында куаклар кисү, чишмәләр һәм сулыкларның ярларын чистарту, авыл эчендәге юлларны һәм башка тышкы төзеклендерү объектларын ремонтлау эшләре.

2. 2020 елга Заречный авыл җирлеге территориясе чикләрендә мәҗбүри яки төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәү өчен объектны – Заречный авыл җирлеге башкарма комитетын җинаятьләрне үтәтү инспекциясе белән килештерү буенча билгеләргә.

3. Әлеге карарны, төзәтү эшләренә хөкем ителгән һәм Заречный авыл җирлеге территориясендә яшәүче затларга карата суд карарлары үтәлешен тәэмин итү өчен, Россия җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Нурлат муниципальара филиалы ФКУнә җибәрергә.

4. Карарны мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта «Заречный авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Заречный авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе З.Х. Низамиев

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 10 декабрендәге 37 номерлы карарына
Килештерү кәгазе

<u>«2020 елга мәҗбүри яки төзәтү эшләре төрләрен һәм 2020 елга төзәтү эшләре рәвешендә административ җәза бирелә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында»</u>
(документның исеме һәм атамасы)

«КИЛЕШЕНДЕ»

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Заречный авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе ___________ _______________

«КИЛЕШЕНДЕ»

Татарстан Республикасы буенча
Россия ҖҮФХИ ФКУнең
Нурлат муниципальара филиалы начальнигы
эчке хезмәт подполковнигы ____________ ________________